ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк. Тел. 3-32-47

# КАРАР

«15» ноябрь 2022 ел №8

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек
торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 25.11.2022 ел Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 25 ноябрь 2022 ел 14.00 сәг. тән 15.00 сәг. кадәр;
- үткәрү урыны – Югары Көек авылы, Тукай ур., 59а йорты янында.

1.3. Татарстан республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71 а йорты;
- сайлау хокукына ия булган Югары Көек торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Югары Көек торак пункты халкына гражданнар җыены турында мәгълүматны мәгълүмати стендлар аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәьәләне раслarга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югары Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта, Түбән Кәек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрүне рөхсәт итәргә.

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Кәек авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Кәек авыл җирлегенең Югары Кәек авылында гражданнар җыенын билгеләү турындагы» 2022 елның 19 октябрендәге 5 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында “Интернет” мәълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Кәек авылы, Татарстан ур., 71 а йорты, Түбән Кәек башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
6. Әлеге каранын үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Кәек авыл җирлеге башлыгы Д.М. Галиәхмәтов